**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«30» 07 2026 ел Яр Чаллы шәһәре №2557

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
«Тукай» спорт мәктәбе» муниципаль
бюджет өстәмә белем бирү
учреждениесен төзү турында

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Тукай» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесен (алга таба – «Тукай» спорт мәктәбе» МБУ) төзергә.
2. «Тукай» спорт мәктәбе» МБУ уставын расларга.
3. «Тукай» спорт мәктәбе» МБУ директоры вазифаларын башкаручы итеп Аббазов Илнар Рафиковичны билгеләргә.
4. И.Р. Аббазовка Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Тукай» спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе уставын теркәргә.
5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. С. Галиуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л. Н. Маняпов